МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.01.2021 г.Казань № 8

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 10 февралендә 7551 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү өчен кулланыла торган документлар формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 466 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү турында килешү формасына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин

итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюдже-тыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү өчен кулланыла торган документлар формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 466 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын компенсацияләү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия-ләр рәвешендә грант бирү турында килешү формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта «31 декабрь 20__ ел» сүзләрен «___» _______20___ел» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктка 1 астөшермәне төшереп калдырырга;

8 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Якларның юридик адреслары, банк реквизитлары һәм имзалары

| Тәэмин итүче | Вәкаләтле орган |
|---|---|
| ________________________________<br>(оешманың тулы исеме (шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме)) | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| ________________________________<br>(тулы почта адресы) | 420044, Казан шәһәре, Волгоград урамы, 47 |
| ________________________________<br>(банк исеме) | БҮЛЕК - РОССИЯ БАНКЫНЫҢ ТР МИЛЛИ БАНКЫ БҮЛЕКЧӘСЕ//Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре |
| и-х счеты________________________ | 03221643920000001100 |
| к/с ________________________________ | 40102810445370000079 |
| БИК ________________________________ | 019205400 |
| ИНН ________________________________ | 1657069000 |
| КПП ________________________________ | 165701001 |
| ОГРН ________________________________ | 1071690050299 |
| ________________________________<br>(банк операцияләре үткәргәндә файдаланыла торган, оешманың кыскартылган исеме) | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы, ЛБ007160002-МинТСЗащ) |
| ________________________________<br>(оешма җитәкчесе вазыйфасының атамасы) | Җитәкче |
| ______ ________________________<br>(оешма җитәкчесенең (шәхси эшкуарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме) | __________ ____________________<br>(Фамилия, исем, ата исеме) |
| М.У. *(Россия Федерациясе законнарында эш* | М.У.». |

*бирүче өчен мөһер булдыру бурычы билгеләнгән очракларда)*

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова